*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**

(2024-2025 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Мөнәҗәтләр турында исеңә төшер. Аларның үзенчәлекләрен барлап яз, мисаллар китер. (7 балл)**

**Җавап:** Ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, ялварып, ярлыкануга нигезләнгән дини эчтәлекле татар халык авыз иҗаты әсәре мөнәҗәт дип атала.

Тематик төркемнәре: а) Аллаһы Тәгаләгә мөрҗәгать итү; ә) туган-үскән илгә бәйле; 3) ана һәм бала мөнәсәбәтләре турында, 4) яшәү һәм үлем турында.

Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Эльмира Шәрифуллина һ.б. мөнәҗәтләр бар.

**2. Рәсемгә игътибар ит. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз, әсәр геройларын ата. (6 балл)**



**Җавап:** Габдулла Тукай. «Пар ат».

Геройлар: Лирик герой, кучер.

**3. Әсәрләрнең авторын, жанрын яз. (6 балл)**

а) «Бездә яздыр» ____________________ __________________

ә) «Моңлы бер җыр» ______________________ _________________

б) «Буранда» ______________________ __________________

**Җавап:**

а) «Бездә яздыр» Фатих Кәрим шигырь

ә) «Моңлы бер җыр» Туфан Миңнуллин драма

б) «Буранда» Шәриф Камал хикәя

4. **Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгелә. (6 балл)**

Авыруыма табиб кирәк түгел,
Йөрәгемнең беләм дәвасын:
Һәр ел саен кайтып иснәп киләм
Авылыбызның чиста һавасын.

Язар өчен илһам эзлә, диләр,

Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.

Никтер минем шигъри хисләремә

Арышларның исе тәмлерәк!

**<u>Җавап:</u>** Сибгат Хәким. «Җырларымда телим...»

Хис-кичерешләр – Туган якка мәхәббәт, аның матурлыгына соклану, аны сагыну хисләре.

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп яз. (10 балл)**



1) ___________________________

2) ___________________________

3) ___________________________

**<u>Җавап:</u>**

1) Мөдәррис Әгъләмов 1946 елның 13 октябрендә Татарстанның Зәй районы Биш Субашы авылында колхозчы гаиләсендә туа.

2) Аның поэзиясенә музыкальлек, татар татар поэзиясе һәм халык иҗаты традицияләреннән үсеп чыккан табигыйлек, эчке бер моң хас.

3) Мөдәррис Әгъләмовка “Киләчәккә кайту” һәм “Мин әйттем...” шигырь китаплары өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә һ.б.

**6. Сыерчык диңгез артына китсә дә үз туган оясына кайта, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**